Шәһәр күләмендә физика фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
10 нчы сыйныф

Эш вакыты – 120 минут
Гомуми балл - 50

1. Һавасын бик тиз рәвештә суырып чыгарып була торган савытта m *г* массалы су бар. Суның температурасы t = 0^0C. Интенсив рәвештә парга әверелү нәтиҗәсендә су, катып, бозга әйләнә. Суның башлангыч массасының нинди өлеше бозга әйләнгән?

2. 125 м биеклектән ирекле төшүче таш, хәрәкәт итүенең соңгы секундында нинди юл үтәр?

3. Горизонтка авышлык почмагы □ = 30□ тигез булган яссылык өстендә массасы m = 20 кг булган таш ята. Ташны яссылык буйлап F = 10 Н көч куеп аска таба тартып төшергәндәге ышкылу коэффициентын исәпләгез.

4. Җылыткыч каршылыклары R1 = R2 = R, R3 = 3R булган 3 элементтан тора. Алар үзара схемада күрсәтелгәнчә тоташтырылганнар. Җылыткыч A һәм B клеммаларына тоташтырылган. Әгәр 15 секунтта R1 каршылыгында Q1 = 160 Дж җылылык микъдары бүленеп чыкса, 1 минутта R3 каршылыгында нинди җылылык микъдары бүленеп чыгар?



5. Жир өслегеннән нинди биеклектә очканда ясалма иярченнең тизлеге 7,6 км/с булыр? Бу иярченнең әйләнү периодын табыгыз.